ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

10 июля 2026года №49

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Техник хатаны бетерү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы 2026 елның 02 июнь 42 номерлы Совет карары белән расланган Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советының 2026 елның 16 июнендәге 47 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә,

1.1. 5 статьяның 6 өлешендә «статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 8 статьяның 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат эшчәнлеге формалары була:

1) җирлек Советы сессияләре эшендә катнашу;

2) җирлек Советының даими комиссияләре эшендә катнашу;

3) федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, барлык оештыру-хокукый рәвештәге оешма җитәкчеләренә, иҗтимагый берләшмәләргә мөрәҗәгать;

4) муниципаль хокукый акт проектын кертү;

5) җирлек Советы тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу;

6) җирлек Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләүдә катнашу;

7) депутат соравын кертү;

8) сайлаучылар белән очрашулар, аларның мөрәҗәгатьләре белән эшләү, үзе вәкил булган җирлек халкына үз эшчәнлеге һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

9) җирле референдумнарны, гавами тыңлауларны, җыелышларны, конференцияләрне һәм гражданнардан сорашып белешүләрне оештыруда һәм уздыруда катнашу;

10) территориаль иҗтимагый үзидарә оештыруда катнашу.».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында(http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук торак пунктның мәгълүмати стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, М.Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Заволжье» ЦКС бинасы), Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (администрациясе бинасы) бастырып чыгарырга.

Норлат авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.М.Саттаров